ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

№2 23 октябрь 2022 ел

2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасында укучы студентлар, махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләрдән тыш, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Мәлбагыш авылында механикалаштырылган кар чистарту хезмәтләре өчен түләү (килешү буенча эшләр өчен түләү) , юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларга хезмәт күрсәтү;
- җәйге чорда Мәлбагыш авылында үлән чабу, территорияне җыештыру буенча хезмәтләр ;
- Мәлбагыш авылында «Сабантуй», «Җиңү көне»” Өлкәннәр көне”, “Инвалидлар көне”, “Яңа ел” бәйрәмнәрен оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу);
- күмелгән урыннарны карап тоту (дератизация, тоташ гербицид белән химик эшкәртү, агач кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, инструментлар һәм җиһазлар сатып алу, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- трактор өчен асылмалы кораллар сатып алу, ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу;
- трактористка хезмәт хакы түләү;
- Мәлбагыш авылында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (электр товарлары сатып алу, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү)

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Мәлбагыш авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Азнакай муниципаль районы
Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгы А.Й.Әхмәтшин